Д гр/К36
ВСЕСОЮЗНАЯ БИБЛ-КА имени В. И. Ленина
Татарский яз.
Маннанов

## ВАТАН СУГЫШЫ ГЕРОЙЛАРЫ

ВАТАНЫБЫЗНЫ НЕМЕЦ ЕРТКЫЧЛАРЫННАН ТАЗАРТУЧЫ ГАЙРӘТЛЕ БАТЫРЛАРЫБЫЗГА ДАН!

50754-0



СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ

# ИЛЬДАР МАННАНОВ

## ХАЛЫК БАТЫРЫ ИЛЬДАР МАННАНОВ

Сугышчы иптәшләр! Татар халкының данлыклы улы Ильдар Маннанов турында сезнең ишеткәнегез бармы? Аның турында сезнең күбегез ишеткәндер, әлбәттә. Татар егетенең Советлар Союзы Герое дигән данлыклы исемен ишетми калырга мөмкинме соң, чөнки аның белән татар халкы гына түгел, бәлки безнең Бөек Ватаныбыздагы барлык тугандаш халыклар да горурланалар. Хәзер инде аның гүзәл тормыш юлы, аның батырлыгы, дошманга карата каты нәфрәте, үз Ватанына ялкынлы мәхәббәте турында сөйләшик.

Ильдар Маннанов 1921 нче елда Татарстанның Калинин районы Буләк авылында туган. Җиде еллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Ильдар комбайнерлар курсына укырга керә. Бу курсларны уңышлы рәвештә тәмамлагач ул үзенең туган җиренә — колхоз кырларына кайта.

Бөек Ватан сугышы башланып киткәндә, Маннанов Кызыл Армия сафларында була. Монда ул үзен үрнәк булырлык дисциплиналы сугышчы итеп күрсәтә. Хәрби эшне өйрәнүдә Маннанов иң алдынгы, иң яхшыларның берсе була. Дәһшәтле корал булып торган артиллерияне ул бик яхшы итеп өйрәнә һәм хәрби эшнең остасы булып әверелә.

Бөек Ватан сугышы башлангач Маннанов хезмәт итә торган часть Карелия фронтына җибәрелә. Данлыклы патриот — татар егете Ильдар Маннановның сугышчан, героик тормышы менә шунда башланып китә.

Бер вакытны аеруча каты һәм канлы сугыш кабынып китте. Пушкалардан ату, бомбалар һәм снарядлар шартлап ярылу тавышларыннан җир тетрәп торды. Гитлерчы бандалар безнең подразделениеләребезнең басымына чыдый алмыйча чигенә башладылар. Ләкин дошман чигенеп барганда нык каршылык күрсәтә иде. Ул һәрбер калкулыкка, һәрбер биеклеккә ябыша, үзенең чигенүен танклар белән каплый һәм безнең полкның һөҗүмен тоткарларга маташа иде.

Сугышның хәл иткеч моменты килеп җитте. Немецлар бик зур өстәмә көчләр китереп контратакага күчтеләр. Дошман артиллериясе гөрелдәде, танклары күренде һәм алар туп-туры безнең позицияләребезгә юнәлделәр.

— Үткәрмәбез! Дошман танклары безгә куркыныч түгел, — диде наводчик Маннанов.

— Үткәрмәбез! — дип бер-берсенә ант иттеләр сугышчан бер семьяга береккән артиллеристлар.

Сугыш яңа көч белән кабына бара. Куркыныч минут саен арта. Дошман снарядлары Маннановның янында ук шартлыйлар. Батырның йөрәгендә ачу һәм дошманга карата көчле нәфрәт кайный һәм ул үзенең сугышчан рус иптәшләре белән берлектә, дошманның техникасын һәм җанлы көчләрен кыруны дәвам иттерә.

Әнә алар, дошманның кара танклары ялкынланып яналар! Менә алар, Гитлерның бөтен Европа аркылы җиңел марш белән үткән, «мактаулы» бронялы машиналары.

Менә тагын берсе яна башлады!.. әнә тагын... әнә, әнә тагын яна... Ләкин көчләр тигез түгел иде. Дошман яңадан-яңа көчләр китерә һәм алга ыргыла.

Маннановка җиңел түгел иде. Маннановның күз алдында аның сугышчан дуслары бер-бер артлы сафтан чыга бардылар, ләкин батыр егет рухын төшермәде. Аның йөрәгендә, ерткыч фашизмга каршы булган нәфрәте тагын да ялкынланыбрак яна башлады. Һәм бу аңа, өстәмә көч бирә иде.

— Орудием төзек чакта, үзем исән чакта һәм күкрәгемдә йөрәгем типкәндә, мин биш кеше өчен, ун кеше өчен, соңгы сулышыма кадәр сугышачакмын! — диде Маннанов.

Ләкин орудие — винтовка түгел, ул дәһшәтле һәм куәтле сугыш машинасы.

Аны цельгә төзәргә һәм корырга, коргач атарга, аннары тагы төзәргә кирәк — бу гади эш түгел. Маннанов арганлыкны җиңеп, орудиенең бөтен расчёты урынына бу эшләрнең барысын да бер үзе башкарды. Орудие янында бер ялгызы калгач — ул аны үзе корды, үзе төзәде һәм дошман танкларына атты. Ул бер үзе, әкияттәге батыр кебек, үзенең кечкенә участогында, дошманның танкларына һәм ерткыч автоматчикларына каршы, гайрәт белән ярсып-ярсып сугышты. Орудиесен калдырып китү турында ул уйлап та карамады. Ул үзенең орудиесе белән бердәм көч булып әверелде. Уң яктан һәм сул яктан һөҗүм итүче подразделениеләрнең булышлыгын сизеп, ул аруны-талуны белмичә дошманны кыруны дәвам итте.

— Канга сусаган немецлар үзләренең җилкәләрендә, татар егетенең гайрәтен һәм аның нәрсәгә сәләтле икәнен татып карасыннар!

Ильдарның орудиесе соңгы чиккә кадәр кызды, ләкин ул үзенең хуҗасына — дустына һич каршылыксыз хезмәт итте. Ильдар, дошманның якын ук килгән танкларына туры наводка белән атты.

Маннановның снарядлары цельнең нәкъ үзәгенә туры тиеп, фашистларның бронясын металл кисәкләре өеменә әйләндерәләр иде.

— Ватанымның даны өчен, халкымның намусы өчен, Бөек Сталин өчен!

Фашистлар өстенә Ильдар 108 снаряд җибәрде. Аның әйләнәсе атылган гильзалар белән тулды. Ә дошман ягында, — безнең җиргә килеп үзенә үлем тапкан йөзләрчә фрицлар аунап яталар иде.

Танклар үтә алмадылар. Дошманның контратакасы тончыкты.

Сугышчылар бик яхшы сугыштылар. Артиллеристлар да әйбәт сугыштылар.

Бу гүзәл операцияне уңышлы үткәргән өчен Хөкүмәт артполкны «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләде. Бу полкның 23 сугышчысы аерым рәвештә бүләкләнделәр. Шулардан 22-се «Кызыл Байрак» ордены белән, ә берсе иң бөек бүләк алуга — Советлар Союзы Герое исмен алуга иреште. Бу егет — татар халкының кыю һәм батыр улы Ильдар Маннанов иде. Хәзер аның күкрәге Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медале белән бизәлгән.

Безнең илебез никадәр геройлар, никадәр батырлар тәрбияләп үстерде. Данлыклы Кызыл Армиябез никадәр батыр сугышчылар, командирлар үстерде.

Ильдар Маннанов казанган данны, элекке заманда татар солдаты казана ала идемени? Патша заманында изелгән һәм кимсетелгән татар халкының улы бу турыда хыялланырга да батырчылык итә алмый иде.

Татарстанның хезмәт ияләре Ильдар Маннановның күрсәткән батырлыклары белән горурланалар. Алар фашист кабахәтләргә каршы көрәштә, аның тагын да зуррак уңышларга ирешүен телиләр.

Татар егетләре, Маннанов кебек батыр булыгыз! Немецлардан үч алыгыз, аларны аяусыз рәвештә кырыгыз!

**ҮЗЕҢ УКЫГАЧ ИПТӘШЕҢӘ БИР!**

**Кызыл Армиянең Политик Баш Управлениесе басмасы.**

ГЛАВНОЕ ПОЛИТИЧЕСКОЕ УПРАВЛЕНИЕ КРАСНОЙ АРМИИ

Листовка посвящена доблестному сыну татарского народа Герою Советского Союза Ильдару Маннанову.

ВОЕНИЗДАТ НКО 1943 г. На татарском языке. Заказ 2642.